**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22.11.2024** **Мәлки ав.** **№ 12**

Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законнар һәм гражданнарның янгыннан саклануын тәэмин итү максатларында, Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәне расларга.
2. Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 31 маендагы 4 номерлы «Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәне раслау хакында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм https://molkeev-kaybici.tatarstan.ru веб- адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мәлки авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Ф.П.Поляков

Мәлки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024е. 22.11. 11 номерлы
карарына кушымта

**Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә эшләнгән һәм Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны оештыру-хокукый, финанс, матди-техник тәэмин итүне билгели.

1.2. Кайбыч муниципаль районының (алга таба - муниципаль берәмлек) Мәлкиавыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә керә.

1.3. Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль законнары нигезендә төгәл файдаланыла.

## 2. Мәлки авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү

2.1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүнең төп бурычлары:

- янгыннарны булдырмау (янгыннарны профилактикалау) чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;
- янгын вакытында кешеләрне һәм мөлкәтне коткару.

2.2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын оештыру ягыннан тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) муниципаль берәмлек территориясендә һәм муниципаль милек объектларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) муниципаль берәмлек чикләрендә янгыннарны сүндерү өчен тәртип, көчләрне һәм чараларны билгеләү;

3) шәһәр төзелешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, муниципаль берәмлек территориясендә планлаштырганда һәм төзегәндә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү;

4) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә пропаганда оештыру, янгын сүндерү-техник белемнәрен таратуга ярдәм итү;

5) кешеләр күп була торган чараларны оештыруны һәм уздыруны тикшереп тору.

2.3. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын финанс белән тәэмин итү шушы максатларга муниципаль берәмлек бюджетында каралган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне күздә тота:

1) янгын куркынычсызлыгы чыгымнары өлешендә җирле бюджетны эшләү, раслау һәм үтәү;

2) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүне социаль һәм матди кызыксындыруны гамәлгә ашыру, шул исәптән халыкның янгыннарга каршы көрәштә катнашуын;

3) муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән түбәндәгеләргә бәйле чыгымнар гамәлгә ашырыла:

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру һәм муниципаль мөлкәтне төзүгә һәм (яисә) арттыруга китерү;

- халык арасында янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары үткәрү;

- Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге башкарма комитеты кабул иткән янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм янгын-техник белемнәрен таратуга ярдәм итү буенча карарлар турында халыкка мәгълүмат бирү.

2.4. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын матди-техник яктан тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) муниципаль милектәге торак һәм иҗтимагый биналарның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын төзек хәлдә тоту эшләрен оештыру;

2) муниципаль берәмлек чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, биналарга, корылмаларга бару юлларын карап тоту һәм янгын урынына янгын техникасының тоткарлыксыз үтүен тәэмин итү;

3) янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының тиешле торышын тәэмин итү;

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын гамәлгә ашыру;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыруга бәйле муниципаль заказлар булдыру һәм урнаштыру.

## 3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү вәкаләтләре

Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Башкарма комитетының торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- янгыннан ирекле саклауны оештыру өчен, шулай ук гражданнарның янгын куркынычсызлыгын башка рәвешләрдә беренчел чараларны тәэмин итүдә катнашуы өчен шартлар тудыру;

- авыл торак пунктларында һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә

урнашкан тышкы су белән тәэмин итү чыганакларыннан елның теләсә кайсы вакытында су җыю өчен шартлар тудыру;

- янгыннарны сүндерүнең беренчел чаралары һәм янгынга каршы инвентарь белән гомуми файдалану территорияләрен тәэмин итү;

- янгын турында Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең халыкка һәм бүлекчәләренә хәбәр итү чараларын оештыру һәм кабул итү;

- янгынны локальләштерү, янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләре килеп җиткәнче кешеләрне һәм мөлкәтне коткару чараларын күрү;

- муниципаль берәмлек территориясен үстерү планнарына, схемаларына һәм программаларына янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын кертү;

- янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат җиткерүдә, шул исәптән халык җыелышларын оештыру һәм уздыру юлы белән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтү;

- янгын куркынычы арткан очракта махсус янгынга каршы режим билгеләү.

## 4. Гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә катнашу формалары

Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу формалары түбәндәгеләр:

- эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;

- алар милкендәге биналарда һәм корылмаларда беренчел янгын сүндерү чаралары булу;

- янгын чыкканда алар турында кичекмәстән янгын сагына хәбәр итү;

- янгын сүндерүчеләр килгәнче кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгынны сүндерү буенча кулдан килгәнчә чаралар күрү;

- янгын сүндергәндә янгын сүндерүчеләргә ярдәм күрсәтү;

- дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

- законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында аларга караган җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны һәм корылмаларны тикшерүләр һәм тикшерүләр уздыру мөмкинлекләрен бирү.